# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең Югары Тәкермән торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**30 ноябрь 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Югары Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән авыл җирлеге Югары Тәкермән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

*1) Югары Тәкермән торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);*

*2) Югары Тәкермән торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Югары Тәкермән торак пунктында су җыю манарасын һәм суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, эшләр өчен түләү) һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр))»;*

*3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Беларус 82.1 тракторына хезмәт күрсәтү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт хакы түләү)*

*4) Югары Тәкермән торак пунктында һәйкәлләр төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучыларга обелиск төзү, мемориаль плитәләр, брусчаткалар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)*

2.Әлеге карарны Югары Тәкермән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми

сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Югары Тәкермән авыл җирлеге башлыгы ________________А.А.Шәрипова